# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Кече Битаман авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

11 декабрь 2023 е. №3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "2003 елның 06 октябрендәге 2131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре буенча, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 22 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән 2023 елның 11 декабрендә 18 сәгать 00 минутта «Сез ризамы:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Кече Битаман торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үз-үзенә салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

1) вак таш сатып алу

2) янгынга каршы гидрант сатып алу һәм урнаштыру

3) урам яктырту җайланмасы

4) күперне ремонтлау

5) чүплекне бетерү

6)агачлар кисү

7) юлларны кышын һәм җәен төзекләндереп тору (трасторчыга хезмәт хакы, ЯММ сатып алу)

2. 2024 елда үзара салым түләүдән азат итү:

өлешчә мобилизация чорында Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары һәм контракт буенча свода хезмәт итүчеләр һәм аларның гаилә әгъзалары

б) 1 төркем инвалидлар

“РИЗА” "КАРШЫ".

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә: Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 130 (берйөз утыз) граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 78 (җитмеш сигез) кеше, бу 78% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленгән: гражданнар җыенында катнашучы 78 (җитмеш сигез) “РИЗА” позициясе өчен тавыш бирә; җыенда катнашучы 0 (ноль) “КАРШЫ” позициясе өчен тавыш бирә. Бу нигездә, гражданнар җыены:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Кече Битаман торак пунктында узган гражданнар җыенын танырга, җыен нәтиҗәләрен гамәлдә дип санарга.

2. 2024 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлегенең Кече Битаман авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими рәвештә аваыл территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә.

3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) вак таш сатып алу

2) урам яктырту җайланмасы

3) чүплекне бетерү

4)агачлар кисү

5) юлларны кышын һәм җәен төзекләндереп тору (трасторчыга хезмәт хакы, ЯММ сатып алу)

6) Кече Битаман авылында юлларга вак таш җәю

4. 2024 елда үзара салым түләүдән азат итәргә:

өлешчә мобилизация чорында Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә чакырылган гражданнарның гаилә әгъзалары һәм контракт буенча свода хезмәт итүчеләр

б) 1 төркем инвалидлар

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм республиканың рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә

Җыен рәисе Ф.Ю.Закиров